ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 147-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 147-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 515-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяга түбәндәге эчтәлекле $38^1$ пункт өстәргә:
«$38^1$) «Татарстан Республикасы буенча Атказанган милли гвардия гаскәрләре хезмәткәре»;»;

2) 14 статьяга түбәндәге эчтәлекле $37^1$ пункт өстәргә:
«$37^1$) «Татарстан Республикасы буенча Атказанган милли гвардия гаскәрләре хезмәткәре» – милли гвардия гаскәрләрендә календарь буенча исәпләгәндә, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел хезмәт итүче Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең югары профессионал хәрби хезмәткәрләренә һәм хезмәткәрләренә дәүләт һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүдәге, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклаудагы, милли гвардия гаскәрләре кадрларын әзерләүдәге һәм тәрбияләүдәге аерым казанышлары өчен;»;

3) 22 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турындагы мәсьәлә белән шәхсән чыгарга хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре өлкәсендә хокук мөнәсәбәтләрен камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Закон проектында Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре төрләренә Татарстан Республикасының яңа дәүләт бүләгеn – «Татарстан Республикасы буенча милли гвардия гаскәрләре Атказанган хезмәткәре» мактаулы исемен өстәү каралган.

Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре турында» 2016 елның 3 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы нигезендә дәүләт һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өчен билгеләнгән дәүләт хәрби оешмасы булып тора.

Күрсәтелгән эшчәнлек өлкәләреннән чыгып, «Татарстан Республикасы буенча милли гвардия гаскәрләре Атказанган хезмәткәре» мактаулы исеме милли гвардия гаскәрләрендә календарь буенча исәпләгәндә, кагыйдә буларак, кимендә 10 ел хезмәт итүче, Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең югары профессионал хәрби хезмәткәрләренә һәм хезмәткәрләренә дәүләт һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итүдәге, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклаудагы, милли гвардия гаскәрләре кадрларын әзерләүдәге һәм тәрбияләүдәге аерым казанышлары өчен бирелә.

Моннан тыш, закон проектында Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турындагы мәсьәләне шәхсән тәкъдим итәргә хокуклы дигән норма карала.

**«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә**
**үз көчен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә**
**яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары**
**һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белешмәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Татарстан Республикасы буенча милли гвардия гаскәрләре Атказанган хезмәткәре» мактаулы исеме белән бүләкләүгә номинантларның фаразлана торган саны 2026 елда якынча 20 кеше тәшкил итәчәк.

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

«Татарстан Республикасы буенча милли гвардия гаскәрләре Атказанган хезмәткәре» мактаулы исеме белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм чаралары (айлык акчалата түләү, торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидияләр, элемтә хезмәтләре, түләүсез теш протезлау һәм ишетү органнарын протезлау) күрсәтү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә каралган акчалар кысаларында гамәлгә ашырылачак.